**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.06.2018** **№ 1153**

**Биектау муниципаль районы территориясендә федераль милектәге, муниципаль торак фондындагы урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле һәм хосусый торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәне раслау хакында” 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарына таянып, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2006 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне, (1 нче кушымта).

1.2. Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия составын, (2 нче кушымта).

1.3. Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану тәртибе турында нигезләмәне, (3 нче кушымта).

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын

үз көчләрен югалткан дип танырга:

- 28.05.2015 №1281 «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында»;

- 24.08.2015 №1643, 16.11.2016 №2395, 19.01.2017 № 4, 24.04.2017 №1125, 25.08.2017 №2106 «ТР Биектау района Башкарма комитетының 28.05.2015 №1281 номерлы «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

1 нче кушымта
ТР Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018
елның 01 июнендәге 1153
номерлы карары белән расланды

**Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия турында**
**нигезләмә**

1. Урынны торак урын, торак урынны яшәргә яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, һәм хосусый торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең эш тәртибен (алга таба - Комиссия) билгели.

2. Комиссиянең төп бурычы булып, Биектау муниципаль районында урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм муниципаль торак фондында күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле һәм хосусый торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану буенча мәсьәләләрне карау тора.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 январендәге 47 номерлы карары белән расланган Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында Нигезләмәгә (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 январендәге 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмә) һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Комиссия урын милекчесенең, бәяли торган мөлкәткә карата милекченең вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органының гаризасы нигезендә йә дәүләт күзәтчелеге (контроле) органнарының үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләре буенча бәяләмәсе нигезендә әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә каралган тәртиптә карар кабул итә.

5. Яшәү урынының яшәү өчен яраклыгы (яраксызлыгы) һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану турындагы мәсьәләне карау өчен мөрәҗәгать итүче торак урынының урнашу урыны буенча Комиссиягә түбәндәге документларны тапшыра:

а) урынны торак урын яки торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм (яки) күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле

итеп тану турында гариза;

б) күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрында торак урынга хокук билгеләүче документларның күчермәләре;

в) аны алга таба торак урыны дип тану өчен торак булмаган бинага карата - торак булмаган урынны реконструкцияләү проекты;

г) күпфатирлы йортны тикшерү уздырган махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе - күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану мәсьәләсе куелган очракта;

д) торак урынның киртәләү һәм күтәреп тору конструкцияләре элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча проект-тикшерү оешмасы бәяләмәсе - мондый бәяләмәне тапшыру торак урынны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә (туры килми) торган дип тану турында карар кабул итү өчен кирәк булган очракта;

е) яшәү шартларының канәгатьләнерлек булмавына гражданнарның гаризалары, хатлары, шикаятьләре - мөрәҗәгать итүче карары буенча.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кәгазь чыганакта шәхсән яисә почта аша “Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып йә электрон документлар рәвешендә тапшыру турында хәбәр итеп (алга таба - бердәм портал) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге ярдәмендә тапшырырга хокуклы.

Электрон документ рәвешендә тапшырыла торган гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан гади электрон имза белән имзалана, ә аңа теркәлә торган электрон документлар көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән әлеге документларны биргән органнарның (оешмаларның) вазыйфаи затлары тарафыннан имзаланырга тиеш (әгәр Россия Федерациясе законнарында мондый документларны имзалау өчен электрон имзаның башка төре билгеләнмәгән булса).

Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән комиссиягә тапшырырга хокуклы.

5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт күзәтчелеге (контроль) органы булса, күрсәтелгән орган комиссиягә үз бәяләмәсен тапшыра, аны караганнан соң комиссия бина милекчесенә әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырырга тәкъдим итә.

5.2. Ведомствоара соратулар нигезендә комиссия ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара электрон хезмәттәшлек региональ системаларын кулланып, ведомствоара шул исәптән электрон рәвештә түбәндәгеләрне ала:

а) күчемсез мөлкәткә хокуклар һәм аның белән алыш-бирешбердәм дәүләт реестрыннан торак урынына хокуклар турында белешмәләр;

б) торак урынның техник паспорты, ә торак булмаган биналар өчен техник план;

в) күрсәтелгән документларны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә тапшыру, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә билгеләнгән торакны таләпләргә туры

килә (туры килми) торган дип тану турында карар кабул итү өчен кирәкле дип танылган очракта, тиешле дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнары бәяләмәсе (акты).

Комиссия бу документларны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә күрсәтелгән дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнарында соратып алырга хокуклы.

5.3. Комиссия Россия Федерациясе торак фондының яисә федераль милектәге күпфатирлы йортның торак урыннарына бәя биргән очракта, комиссия эшли башлаганчы 20 көннән дә соңга калмыйча, җирле үзидарә органы тапшырылуы турында хәбәр итеп, язма рәвештә почта аша, шулай ук бердәм порталдан файдаланып, электрон документ рәвешендә Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең бәяләнә торган мөлкәткә карата милекченең вәкаләтләрен башкаручы федераль органына һәм мондый мөлкәткә хокукка ия булучыга комиссия эшли башлау датасы турында хәбәрнамә җибәрергә, шулай ук мондый хәбәрнамәне «Интернет» мәгълүмат челтәрендә дәүләт милке белән идарә итү буенча ведомствоара порталда урнаштырырга тиеш.

Тикшерелә торган мөлкәткә карата милекченең вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы һәм мондый мөлкәтнең хокук иясе комиссия эшли башлау датасы турында хәбәрнамә алган көннән алып 5 көн эчендә комиссиягә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша, шулай ук бердәм портал аша электрон документ рәвешендә комиссия эшендә катнашуга вәкаләтле вәкиле турында мәгълүматны юллыйлар.

Вәкаләтле вәкилләр комиссия эшендә катнашмаган очракта (комиссия эшен башлау датасы турында әлеге пунктта билгеләнгән хәбәрнамә тәртибен үтәгән очракта), комиссия күрсәтелгән вәкилләр булмаганда карар кабул итә.

6. Комиссия кергән гаризаны яисә күзәтчелек (контроль) органы бәяләмәсен теркәлү датасыннан 30 көн эчендә карый һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 47 пункты нигезендә карар (бәяләмә рәвешендә), йә бәяләнгән урынны өстәмә тикшерүне уздыру турында карар кабул итә.

7. Эш барышында комиссия өстәмә тикшерүләр һәм сынаулар билгеләргә хокуклы, аларның нәтиҗәләре комиссия каравына элек тәкъдим ителгән документларга теркәлә.

8. Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган документларны тапшырмаган очракта, һәм ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларын кулланып, ведомствоара соратулар нигезендә аларны соратып алу мөмкин булмаса, комиссия гаризаны карамыйча кире кайтара һәм тиешле документларны әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында каралган срок тәмамланган көннән соң 15 көн эчендә кире кайтара.

9. Эш нәтиҗәләре буенча Комиссия Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә урыннарның һәм күпфатирлы йортларның туры килүен бәяләү турында түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- эксплуатацияләү процессында торак урынның югалган характеристикаларын әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры китерү максатында бинаны капиталь

ремонтланырга, реконструкцияләргә яисә яңадан планлаштырырга тиешле дип тану өчен (техник-икътисадый нигезләргә кирәк булганда) нигезләрне ачыклау турында;

- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану өчен һәм реконструкцияләнергә тиешле нигезләрне ачыклау турында;

- күпфатирлы йортның урынын авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану өчен нигезләр ачыклау турында;

- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле нигезләр булмау турында.

Карар Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм, карар кабул итүнең тиешле нигезләрен күрсәтеп, 3 нөсхәдә бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Әгәр карар кабул ителгәндә "әйе" һәм "каршы" тавышлар саны тигез булса, хәлиткеч булып Комиссия рәисе тавышы тора. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Комиссия әгъзалары үзенең аерым фикерен язма рәвештә белдерергә һәм аны бәяләмәгә кушымта итәргә хокуклы.

10. Бүлмәне тикшергән очракта, комиссия әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә бинаны тикшерү актының 3 нөсхәсен тәшкил итә.

Алынган бәяләмә нигезендә җирле үзидарә органы үзе билгеләгән тәртиптә бәяләмә алган көннән алып 30 көн эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә каралган карар кабул итә һәм, йортны авария хәлендә дип таныган һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле яисә ремонт-торгызу эшләрен башкару кирәклеген таныган очракта, бинаны, физик һәм юридик затларны күчерү срокларын алга таба куллану турында күрсәтмә бастырып чыгара

11. Күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип танылган очракта, торак урыннарны наемлау һәм арендалау шартнамәләре законнар нигезендә өзелә.

Яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннарга шартнамәләр законнар нигезендә суд тәртибендә шартнамәнең теләсә кайсы ягы таләбе буенча өзелергә мөмкин.

12. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында каралган карар кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталын яисә региональ порталын (ул булганда) кертеп, гариза бирүчегә комиссия күрсәтмәсенең һәм бәяләмәсенең 1 әр нөсхәсен, язма яисә электрон рәвештә җибәрә, шулай ук торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм реконструкцияләнергә тиешле дип таныган очракта - мондый бина яисә йорт урнашкан урындагы дәүләт торак күзәтчелеге (муниципаль торак контроле) органына.

Кеше гомере һәм сәламәтлеге өчен аеруча куркыныч тудыручы яшәү тирәлеге факторларының зарарлы йогынтысы булу сәбәпле, йә авария хәлендә булу сәбәпле бинаның җимерелүе куркынычын тудырган очракта, яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә каралган нигезләрдә, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр ачыкланган очракта, әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында каралган карар

тиешле федераль башкарма хакимият органына, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органына, җирле үзидарә органына, торак милекчесенә һәм мөрәҗәгать итүчегә карарны рәсмиләштерү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Аны файдалануга кертү турында рөхсәт бирелгән көннән алып 5 ел эчендә стихияле бәла-казаларга һәм башка хәл итеп булмаслык хәлләргә бәйле булмаган сәбәпләр буенча күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле (андагы торак урыннарны яшәү өчен яраксыз) дип танылган очракта, әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында каралган карар, Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кабул итү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, 5 көн эчендә прокуратура органнарына җибәрелә.

13. Комиссия рәисе Комиссия эше белән гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра, аның эшчәнлеген планлаштыра, утырышлар алып бара, Комиссия кабул иткән карарларның гамәлгә ашырылуын тикшереп тора. Рәис булмаганда, Комиссия эше белән Комиссия рәисенең урынбасары җитәкчелек итә.

14. Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышында карауга материаллар әзерләүне гамәлгә ашыра;

- Комиссия әгъзаларына утырышны уздыру датасы, датасы, вакыты турында, утырышны уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә;

- Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

- Комиссия эше нәтиҗәләре турында документлар әзерли: мәгълүмати белешмәләр, беркетмәләр һәм беркетмәләрдән, актлардан, бәяләмәләрдән өземтәләр, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының карарлары проектларын, мөрәҗәгать итүчеләрнең бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз), шулай ук Биектау муниципаль районында муниципаль торак фондындагы күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, хосусый торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану мәсьәләләре буенча хатлар.

15. Комиссиягә җибәрелә торган гаризаларны, соратуларны кабул итү, теркәү һәм исәпкә алуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге гамәлгә ашыра.

2 нче кушымта
ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 01 июнендәге 1153 номерлы карары белән расланды

**Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия**
**составы**

| | |
|---|---|
| Шәйдуллин Дамир Фәрит улы | Район Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Хәсбеев Равил Равил улы | Муниципаль район Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе комиссия рәисе урынбасары; |
| Зәйнетдинов Динар Илдар улы | район Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы комиссия секретаре; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Сабитов Рамил Фаил улы | Татарстан Республики БТИ АҖ Биектау бүлекчәсе җитәкчесе; |
| Арефьева Елена Николаевна | ТР Дәүләт торак инспекциясенең үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы; |
| Шакирҗанов Артур Марсель улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының территориаль үзәк идарәсенең беренче разрядлы белгече; |
| Аликов Егор Иванович | Татарстан Республикасы буенча Россия МЧС баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсенең Биектау муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре бүлегенең өлкән инспекторы; |
| Шәмсетдинов Илдар Мансур улы | Ростехнадзорның Идел буе идарәсенең Идел буе территориаль бүлегенең Дәүләт инспекторы; |

| | |
|---|---|
| Салкова Эльвира Валентиновна | Роспотребнадзорның Биектау, Арча муниципаль районнары буенча идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы |

Комиссия эшенә җәлеп ителәләр:

- торак урын милекчесе (ул вәкаләт биргән зат) (киңәш бирү тавышы хокукы белән);
- кирәкле очракларда - проект-эзләнү оешмаларының (хәлиткеч тавыш хокукына ия) квалификацияле экспертлары.

3 нче кушымта
ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 01 июнендәге 1153 номерлы карары белән расланды

**Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы «Торакны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә эшләнгән һәм нинди милек рәвешенә карамастан, бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану яисә реконструкцияләү тәртибен билгели, капиталь төзелеш объектларында урнашкан, аларны файдалануга тапшыру һәм дәүләт исәбенә кую Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә гамәлгә ашырылмаган торак биналардан тыш.

2. Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы мәсьәләләр Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия тарафыннан хәл ителә.

3. Комиссия урын милекчесенең гаризасы яисә гражданның (яллаучының) гаризасы нигезендә йә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген уздыруга вәкаләтле органнарның үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча бәяләмәсе нигезендә бинаның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы «Торакны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләүне үткәрә һәм торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип таный, шулай ук күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип таный.

4. Файдаланудагы урынны билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләгәндә аның факттагы торышы тикшерелә.

5. Урынның билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләүне уздыру процедурасына түбәндәгеләр керә:

- гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган нигезләү документларын кабул итү һәм карау;

- торак урынын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы «Торакны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә

тиешле дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) тану турында карар кабул итү өчен кирәкле өстәмә документлар исемлеген билгеләү (тиешле дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнары бәяләмәсе, торак урынны бүлү һәм алып күтреп торучы конструкцияләр элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча проект-тикшерү оешмасы бәяләмәсе, Россия Федерациясе субъекты торак инспекциясенең торак урынына карата уздырылган контроль чараларының нәтиҗәләре турында акты);

- җәлеп ителә торган экспертлар составын билгеләү;

- даими яшәү өчен торак биналарның яраклылыгын (яраксызлыгын) бәяләү буенча Комиссия эше;

- Комиссия тарафыннан торак урынны билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) һәм яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында бәяләмә төзү;

- бинаны тикшерү актын төзү (тикшерү үткәрү кирәклеге турында комиссия тарафыннан карар кабул ителгән очракта) һәм актта күрсәтелгән нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр нигезендә бәяләмә төзү. Шул ук вакытта күпфатирлы йорт Комиссия тарафыннан авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану бары тик тикшерү уздыручы махсуслаштырылган оешма бәяләмәсендә бәян ителгән нәтиҗәләргә генә нигезләнергә мөмкин;

- мөрәҗәгать итүчегә һәм торак урыны милекчесенә карарның берәр нөсхәсен тапшыру (өченче нөсхә комиссия төзегән эштә кала).

6. Торак урынның яшәү өчен яраклылыгы (яраксызлыгы) һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану турындагы мәсьәләне карау өчен мөрәҗәгать итүче Комиссиягә гариза белән бергә түбәндәге документларны тапшыра:

- торак бинага хокук билгели торган документларның нотариаль таныкланган күчермәләре;

- техник паспорты белән торак урыны планы, ә торак булмаган бина өчен - аны алга таба торак урыны дип тану өчен торак булмаган урынны реконструкцияләү проекты.

Күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану өчен шулай ук әлеге йортны тикшерү уздыручы махсуслаштырылган оешманың бәяләмәсе дә тәкъдим ителә.

Мөрәҗәгать итүче карары буенча шулай ук гариза, хатлар, гражданнарның канәгатьләнерлек булмаган яшәү шартларына шикаятьләре дә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче булып дәүләт контролен һәм күзәтчелеген уздыруга вәкаләтле орган торган очракта, Комиссиягә әлеге орган бәяләмәсе тапшырыла, аны караганнан соң, Комиссия бина милекчесенә күрсәтелгән документларны тапшырырга тәкъдим итә.

7. Комиссия дәүләт контролен һәм күзәтчелеген уздыруга вәкаләтле орган гаризасын яисә бәяләмәсен теркәлү көненнән алып 30 көн эчендә карый һәм әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән карарны (нәтиҗә рәвешендә) кабул итә йә бәяләнгән урынны өстәмә тикшерүне уздыру турында карар кабул итә.

Эш барышында Комиссия өстәмә тикшерүләр һәм сынаулар билгеләргә хокуклы, аларның нәтиҗәләре Комиссия каравына элек тәкъдим ителгән

документларга теркәлә.

8. Эш нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- торак урынына куела торган таләпләргә һәм аның яшәү өчен яраклылыгына туры килүе турында;

- эксплуатацияләү процессында югалган торак урын характеристикаларын әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры китерү максатыннан капиталь ремонт, реконструкцияләү яисә яңадан планлаштыру (техник-икътисадый нигезләү белән кирәк булганда) кирәклеге һәм мөмкинлеге турында һәм алар тәмамланганнан соң - бәяләү процедурасын дәвам итү турында;

-бинаның торак бинага куела торган таләпләргә туры килмәве турында, бина яшәү өчен яраксыз дип таныла торган нигезләрне күрсәтеп;

- күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турында;

- күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында.

Карар Комиссия утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Әгәр карар кабул ителгәндә "әйе" һәм "каршы" тавышлар саны тигез булса, комиссиянең рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, рәис урынбасары, секретаре, Комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язма рәвештә белдерергә һәм аны бәяләмәгә кушымта итәргә хокуклы.

9. Эш тәмамланганнан соң, Комиссия 3 нөсхәдә бинаны әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә даими яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында бәяләмә төзи.

10. Урынны тикшергән очракта Комиссия әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә 3 нөсхәдә бинаны тикшерү актын төзи.

Алынган бәяләмә нигезендә Биектау муниципаль районы башкарма комитеты, бинаны алга таба куллану турында күрсәтмә белән, йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип таныган очракта физик һәм юридик затларны урыннарыннан күчерү срокларын күрсәтеп, яисә реконструкцияләнергә яки ремонт-торгызу эшләрен башкару кирәклеген тану турында карар кабул итә һәм карар чыгара.

11. Күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип танылган очракта торак урыннарны наемлау һәм арендалау законнары нигезендә өзелә. Яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннарга шартнамәләр законнар нигезендә суд тәртибендә шартнамәнең теләсә кайсы ягы таләбе буенча өзелергә мөмкин.

12. Комиссия 5 көн эчендә Комиссия карарының һәм бәяләмәсенең 1 әр нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Торак урынны яшәү тирәлеге факторларының кеше гомере һәм сәламәтлеге өчен аеруча куркыныч тудыручы йә аның авария хәлендәге хәле аркасында бина җимерелү куркынычы булу сәбәпле яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта, карар Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә, торак милекчеләренә һәм мөрәҗәгать итүчегә карарны рәсмиләштергән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

13. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карарына карата

кызыксынучы затлар суд тәртибендә шикаять бирергә мөмкин.

14. Торак урынны капиталь ремонтлау, реконструкцияләү яисә яңадан планлаштыру бәяләмә нигезендә кабул ителгән карар нигезендә башкарылган очракта, Комиссия торак урын милекчеләре яисә вәкаләтле затлар тарафыннан аларны тәгәлләү турында хәбәр ителгәннән соң бер ай эчендә торак урынны карый, тикшерү акты төзи һәм тиешле карар кабул итә, ул кызыксынучы затларга җиткерелә.

15. Авыруга бәйле рәвештә кресло-коляскалардан файдаланучы инвалидлар һәм халыкның башка аз мобильле төркемнәре өчен, алар билгән аерым торак биналар (фатир, бүлмә) гражданнар гаризасы буенча һәм авыруларга туры китереп медицина документлары тапшыру нигезендә Комиссия тарафыннан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына яшәү өчен яраксыз дип танылырга мөмкин. Комиссия 3 нөсхәдә күрсәтелгән гражданнарның яшәү өчен яраксыз дип тану турында бәяләмә рәсмиләштерә һәм 5 көн эчендә 1 нөсхәне Биектау муниципаль районы башкарма комитетына, мөрәҗәгать итүчегә икенче нөсхәне җибәрә (өченче нөсхә комиссия төзегән эштә кала).

Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Урынның (күпфатирлы йортның) урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану тәртибе турында нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында бәяләмә**

«__»______________, 20__ел № ________

________________________________________________________________________

(бинаның урнашкан урыны, шул исәптән торак пункт һәм урам исеме, йорт һәм фатир номерлары)

Биектау муниипаль районы Башкарма комитетының _«Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында»______ №___ карары белән расланган Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссиясе түбәндәгеләр составында рәис____

________________________________________________________________________

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм комиссия әгъзалары _______________________________________________

________________________________________________________________________

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар катнашында_____________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм урынның чакырылган милекчесе яки аның вәкаләтле вәкиле

________________________________________________________________________

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

каралган документлар нәтиҗәләре буенча ________________________________

________________________________________________________________________

(документлар исемлеге китерелә)

һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелгән ведомствоара комиссия акты нигезендә , ___________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(тикшерү актыннан алынган (тикшерү үткәрелгән очракта) бәяләмә китерелә, яисә ведомствоара комиссия карары нигезендә тикшерү үткәрелмәгән дип күрсәтелә)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

________________________________________турында бәяләмә кабул итте.

(урынның (күпфатирлы йортның) урынны торак урын, торак урынын яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында ведомствоара комиссия кабул иткән бәяләмәнең нигезләү китерелә)

Бәяләмәгә кушымта:

а) каралган документлар исемлеге;

б) урынны тикшерү акты (тикшерү үткәрелгән очракта);

в) ведомствоара комиссия тарафыннан соратып алынган башка материаллар исемлеге;

г) ведомствоара комиссия әгъзаларының аерым фикере:

_______________________________________________________________________________.

Ведомствоара комиссия рәисе

_________________________ ______________________________________

(имза) (Ф.И.А.)

Ведомствоара комиссия әгъзалары

_________________________ ______________________________________

(имза) (Ф.И.А.)

_________________________ ______________________________________

(имза) (Ф.И.А.)

Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

# УРЫННЫ ТИКШЕРҮ АКТЫ

«___»______________,20__ел №__________

(бинаның урнашкан урыны, шул исәптән торак пункт һәм урам исеме, йорт һәм фатир номерлары)

Биектау муниипаль районы Башкарма комитетының «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында» ______ №_____ карары белән расланган Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссиясе түбәндәгеләр составында:

рәис ____________________________________________________________

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм комиссия әгъзалары_____________________________________________

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар катнашында______________________________________

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм урынның чакырылган милекчесе яки аның вәкаләтле вәкиле

(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

түбәндәге гариза буенча урынны тикшерү уздырды________________________

(мөрәҗәгать итүченең реквизитлары: Ф.И.А. һәм адресы - физик зат өчен, оешма исеме һәм биләгән вазыйфасы - юридик зат өчен)

һәм әлеге урынны тикшерү актын төзеде________________________________

___________________________________________________________________________
(урынның адресы, кемгә каравы, кадастр номеры, эксплуатациягә кертелгән елы)

Торак урынның, бинаның инженерлык системалары, җиһазларның һәм механизмнарның һәм бина янындагы территориянең торышын кыскача тасвирлау

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Күрсәткечнең факттагы билгеләрен яисә конкрет туры килмәүне тасвирлап, билгеләнгән таләпләргә туры килмәүләре турында белешмәләр__________________

____________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Башкарылган инструменталь контроль һәм тикшерүнең башка төрләре нәтиҗәләрен бәяләү _____________________________________________________________________

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(контроль (сынау) кем тарафыннан үткәрелде, нинди күрсәткечләр буенча, нинди фактик кыйммәтләр алынган)

Ведомствоара комиссия киңәшләре һәм даими яшәү өчен иминлек тәэмин итү яки нормаль шартлар булдыру өчен кирәкле тәкъдим ителә торган чаралар____

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Урынны тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе _______

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Актка кушымта:
а) инструменталь контроль нәтиҗәләре;
б) лаборатор сынаулар нәтиҗәләре;
в) тикшеренүләр нәтиҗәләре;
г) проект-тикшеренү һәм махсуслаштырылган оешмалар экспертлары бәяләмәсе;
д) ведомствоара комиссия карары буенча башка материаллар.

Комиссия рәисе

____________________ ________________________________________
(имза) (Ф.И.А.)

Комиссия әгъзалары:

________________________ __________________________________________________
(имза) (Ф.И.А)

________________________ __________________________________________________
(имза) (Ф.И.А)

________________________ __________________________________________________
(имза) (Ф.И.А)

________________________ __________________________________________________
(имза) (Ф.И.А)

________________________ __________________________________________________
(имза) (Ф.И.А)

________________________ __________________________________________________
(имза) (Ф.И.А)